ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.09.2021 № 1372

Алабуга муниципаль районында жирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 03 сентябрендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 сентябрендәге 699 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләргә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.Р. Миңлебаевка йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
"1372" 27 09 ел
карарына 1 нче кушымта

Алабуга муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян күләме күрсәткечләре.

Рөхсәт ителгән массаның иң чик күрсәткенченнән артып киткән очракта авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян күләме

1 нче таблица

| № т/б | Транспорт чарасының рөхсәт ителгән иң чик массасын арттыру (процентларда) | Зыян күләме (100 км га сум) |
|---|---|---|
| 1 | 10 гә кадәр | 2850 |
| 2 | 10нан 20гә кадәр | 3260 |
| 3 | 20 дән 30 га кадәр | 3668 |
| 4 | 30дан 40 ка кадәр | 4078 |
| 5 | 40 тан 50 гә кадәр | 4486 |
| 6 | 50 дән 60 ка кадәр | 4896 |
| 7 | 60 тан югары (артык) | Транспорт чаралары китерә торган зыянның күләме, рөхсәт ителгән массаның күрсәткечләрен арттырганда, 60 %тан югары (артык) булган очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 сентябрендәге 699 номерлы карарында күрсәтелгән формула буенча исәпләнә. |

Иң чик мөмкмн булган күчәр йөкләнешләренең күрсәткечләрен арттырганда авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыянның күләме

2 нче таблица

| № т/б | Рөхсәт ителгән массаның иң чик күрсәткенченнән артып киткән очракта авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян | Зыян күләме, 100 км га сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Рөхсәт ителгән күчәр йөкләнеше 6 т/күчәр | ТРөхсәт ителгән күчәр йөкләнеше 10 т/күчәр | Рөхсәт ителгән күчәр йөкләнеше 11,5 т/күчәр |
| 1 | 10 гә кадәр | 5002 | 1288 | 550 |
| 2 | 10нан 20гә кадәр | 5925 | 2059 | 797 |
| 3 | 20 дән 30 га кадәр | 7403 | 3294 | 1193 |
| 4 | 30дан 40 ка кадәр | 9419 | 4978 | 1732 |
| 5 | 40 тан 50 гә кадәр | 11959 | 7099 | 2411 |
| 6 | 50 дән 60 ка кадәр | 15013 | 9651 | 3228 |
| 7 | 60 тан югары (артык) | Транспорт чаралары китерә торган зыянның күләме, рөхсәт ителгән күчәр йөкләнеше (6, 10, 11,5 тонна/күчәр) булган очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 сентябрендәге 699 номерлы карарында күрсәтелгән формула буенча исәпләнә | | |